**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 сентябрендәге 3052 номерлы карары**

**2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадалары нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре белем бирү оешмалары укытучыларын һәм өстәмә белем бирү педагогларын бүләкләү турында**

«2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында, 2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән белем бирү оешмалары укытучыларын һәм өстәмә белем бирү педагогларын кызыксындыру һәм стимуллаштыру максатыннан **карар бирәм**:

1. 2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән белем бирү оешмалары укытучыларына һәм өстәмә белем бирү педагогларына 2025 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген билгеләргә.

2. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә 2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән белем бирү оешмалары укытучыларына һәм өстәмә белем бирү педагогларына Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген билгеләү һәм түләү тәртибен расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

3.1. 2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучылар һәм өстәмә белем бирү педагоглары турында мәгълүматларны гомумиләштерергә;

3.2. Өстәмә белем бирү укытучыларын һәм педагогларын акчалата бүләкләү чыгымнарын 2025 елга Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең бюджет язмасында каралган ассигнованиеләр чикләрендә

«Мәгарифне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар, гомумшәһәр чаралары» 02 6 02 43600 максатчан статьясы, 0709 бүлеге буенча 12 155 000 сум күләмендә Казан шәһәре бюджетының калган акчалары исәбеннән тормышка ашырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 16 августындагы 3382 номерлы «2024 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадалары нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре белем бирү оешмалары укытучыларын һәм өстәмә белем бирү педагогларын бүләкләү турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
22 сентябрендәге 3052
номерлы карарына
кушымта

**2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләүче укытучыларга һәм өстәмә белем бирү педагогларына Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген билгеләү һәм тапшыру тәртибе**

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләге 2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга һәм өстәмә белем бирү педагогларына булышлык итү һәм аларны кызыксындыру максатыннан бирелә.

2. 2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләге 2025 елда 8 нче сыйныф укучылары өчен (бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының 24 предметы) республика мәктәп укучылары олимпиадасында, геология, Татарстан тарихы буенча республика мәктәп укучылары олимпиадасында, 7–11 нче сыйныф укучылары өчен (туган телдә белем бирә торган мәктәпләр укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр) республика олимпиадасында, бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк һәм йомгаклау этапларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укытучыларына, Казан шәһәре муниципаль өстәмә белем бирү учреждениеләренең өстәмә белем бирү педагогларына, шулай ук «Казан (Идел буе) Федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге лицее» гомуми белем бирү интернат-мәктәбе, «Казан (Идел буе) Федераль университетының IT-лицее» гомуми белем бирү интернат-мәктәбе, «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе, «Казан шәһәре халыкара мәктәбе» коммерциягә нигезләнмәгән автоном гомуми белем бирү оешмасы, Казан шәһәренең «“Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл” күптелле мәгариф комплексы» дәүләт автоном гомуми белем учреждениесе, «Бала-Сити Академиясе (Балалар шәһәре)» коммерцияле булмаган автоном

гомуми белем бирү оешмасы, «Елена-Сервис» урта гомуми белем бирү мәктәбе шәхси гомуми белем бирү учреждениесе, «Казан милли тикшеренү технология университеты-Казан авиация институтының инженерлык лицей-интернаты» махсуслаштырылган фәнни-өйрәнү үзәге укытучыларына түләнә.

3. Акчалата түләү шәхси характерда.

Акчалата түләү күләме әлеге карар белән билгеләнә һәм укучының иң югары нәтиҗәләре буенча түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен (бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының 24 предметы) республика мәктәп укучылары олимпиадасында, геология, Татарстан тарихы буенча республика мәктәп укучылары олимпиадасында, 7–11 нче сыйныф укучылары өчен (туган телдә белем бирә торган мәктәпләр укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр) республика олимпиадасында, бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк һәм йомгаклау этапларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына акчалата бүләкләр, әзерләнгән һәм җиңүчеләр һәм призерлар дип танылган укучылар санына бәйсез рәвештә, бер призлы урын өчен генә бирелә.

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына акчалата бүләкләр әзерләнгән укучылар – җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча бирелә.

Акчалата бүләкләрнең күләме:

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына – 25 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- 7–11 нче сыйныф укучылары өчен (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр) республика олимпиадасында һәм бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына – 15 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- 8 нче сыйныф укучылары өчен (бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының 24 предметы) республика мәктәп укучылары олимпиадасында геология, Татарстан тарихы буенча республика мәктәп укучылары олимпиадасында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына – 5 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп).

Акчалата түләү әлеге тәртипнең 2 пунктында санап кителгән оешмалар төп эш урыны булып тора торган укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына бирелә.

4. 2025 елның 25 сентябренә кадәр бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән һәм акчалата бүләкләү алуга дәгъва кылучы укытучы яки өстәмә белем бирү педагогы эш урыны буенча түбәндәге документларны кулдан тапшыра:

- әлеге тәртипнең 1 номерлы кушымтасындагы форма буенча гариза;

- яшәү урыны буенча теркәлү турындагы тамга белән паспорт күчермәсе;

- физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);

- мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС) мәгълүматлары;

- Россия кредит оешмасында ачылган, түләү башкарылачак счетның реквизитлары;

- әлеге тәртипнең 2 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Кирәкле документлар исемлеге турында мәгълүмат Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең (алга таба – Идарә) рәсми порталында (www.obrazovanie.kzn.ru) әлеге карарны раслау көненнән башлап өч эш көне эчендә урнаштырыла.

Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгариф учреждениеләре 2025 елның 26 сентябренә кадәр әлеге пунктта күрсәтелгән документларны кулдан Идарәгә тапшыралар.

5. Идарә 2025 елның 3 октябренә кадәр әлеге тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплектлы булуын, тулылыгын һәм аларда булган мәгълүматның дөреслеген карап тикшерә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының республика олимпиадасының йомгаклау этабы һәм Бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабы нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы укучылары командасын бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына җибәрү турындагы боерык документлары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре турында боерык документлары нигезендә мәктәп укучыларының казанышларының дөреслеген тикшерә һәм акчалата бүләк алучыларның исемлекләрен төзи.

Акчалата түләү алучылар исемлекләренә әлеге тәртипнең 2 пунктында санап кителгән оешмалар төп эш урыны булып тора торган, әлеге тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган һәм призерларны һәм җиңүчеләрне әзерләгән укытучылар һәм өстәмә белем бирү педагоглары кертелә:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасы, 7–11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (туган телдә белем ала торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр), бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабы нәтиҗәләре буенча – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары нигезендә;

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре буенча – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы әмерләре нигезендә.

2025 елның 15 октябренә кадәр Идарә башлыгы әмере белән акчалата бүләкләү алучыларның исемлекләре раслана.

6. Акчалата түләү алучыларның исемлекләрен раслый торган Идарә боерыгы акчалата бүләкне бирү өчен нигез булып тора.

Акчалата түләү боерык басылып чыккан көннән алып ике ай эчендә укытучының яки өстәмә белем бирүче педагогының исәп-хисап счетына акчалар күчерү юлы белән Идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләүче укытучыларга һәм өстәмә белем бирү педагогларына Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген билгеләү һәм тапшыру тәртибенә
1 номерлы кушымта
(Форма)

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы
И.А.Ризвановка

_____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
_____________________________________________
_____________________________________________
(туган көне, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары)
_____________________________________________
(элемтә өчен телефон)

Гариза

2025 елда мәктәп укучыларының бөтенроссия һәм республика олимпиадалары җиңүчеләрен һәм призерларын әзерләгән өчен миңа тиешле акчалата бүләкне түбәндәге реквизитлар буенча банк картасына күчерүегезне сорыйм:

- исәп-хисап счеты _______________________________________________
- банкның исеме _________________________________________________
- БИК _____________________________________________________
- корреспондент счеты ____________________________________________
- салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) ________________________
- КПП _____________________________________________________

____________________
(дата)
__________________
(имза)

2025 елда бөтенроссия һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләүче укытучыларга һәм өстәмә белем бирү педагогларына Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген билгеләү һәм тапшыру тәртибенә
2 номерлы кушымта
(Форма)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,__________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ______________________________________________,
паспорт сериясе _______ номеры __________ ________ елның «___» ___________ бирелгән
(бирелү вакыты)

___________________________________________________________________________
(документны биргән органның атамасы)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә 2025 елда бөтенроссия һәм республика олимпиадалары җиңүчеләрен әзерләгән укытучыларга һәм өстәмә белем бирү педагогларына бирелә торган Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең акчалата бүләген алу максатыннан, операторга – 420111, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру (тарату, бирү, куллануга рөхсәт бирү), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блок кую, бетерү, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруга ризалыгымны бирәм, аерым алганда:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), адресы, паспорт мәгълүматлары;

2) банк счеты реквизитлары;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН);

4) мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС).

Миңа шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы булуым турында аңлатылды.

Килешү аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм аны язма рәвештә кайтарып алганчы билгесез вакыт эчендә гамәлдә була.

___________________________________________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү көне: «____» ____________ 20___ ел